**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**9 декабрь 2022 ел** **№ 235**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегенең генераль планын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, 3 өлеше нигезендә, 08.11.2022 ел. гавами тыңлаулар беркетмәсен, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча 08.11.2022 узган ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планын кушымта нигезендә расларга.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетына «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планын территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырырга (халыкка җиткерергә).

4. Бу карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
муниципаль район башлыгы Р. Ф. Хисамутдинов

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы материаллары белән Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында https://fgis-tp.ru вин буенча танышырга мөмкин.